МИНИСТЕРСТВО КУЛЬТУРЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘДӘНИЯТ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

09.02.2017 г. Казань № 120 од

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының Рәсем сәнгате, декоратив-гамәли сәнгать һәм сәнгать белеме өлкәсендә Бакый Урманче исемендәге премиясен алу өчен республика конкурсы турында нигезләмәне раслау турында

Татарстан Республикасының заманча рәсем сәнгатенә ярдәм максатыннан

**БОЕРАМ:**

1. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының Рәсем сәнгате, декоратив-гамәли сәнгать һәм сәнгать белеме өлкәсендә Бакый Урманче исемендәге премиясен алу өчен республика конкурсы турында теркәлгән нигезләмәне (алга таба – Нигезләмә) расларга.
2. Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

**Министр** **А.М.Сибагатуллин**

Татарстан Республикасы
Мәдәният министрлыгының
__________ ______номерлы
боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының Рәсем сәнгате, декоратив-гамәли сәнгать һәм сәнгать белеме өлкәсендә Бакый Урманче исемендәге премиясен алу өчен республика конкурсы турында
НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының Рәсем сәнгате, декоратив-гамәли сәнгать һәм сәнгать белеме өлкәсендә Бакый Урманче исемендәге премиясен алу өчен республика конкурсы турында әлеге нигезләмә (алга таба - Нигезләмә) Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының Рәсем сәнгате, декоратив-гамәли сәнгать һәм сәнгать белеме өлкәсендә Бакый Урманче исемендәге премиясен алу өчен республика конкурсы (алга таба – конкурс) үткәрүнең максатларын, бурычларын һәм тәртибен билгели.

1.2. Конкурс түбәндәге номинацияләр буенча үткәрелә:

«Рәсем сәнгате» (номинациядә фигуратив һәм предметсыз характердагы төрле техника һәм жанрларда башкарылган станоклы рәсем сәнгате һәм монументаль композицияләр эскизлары, сценография карала;

«Графика» (номинациядә оригиналь графика әсәрләре (карандаш, каләм, күмер, сангина, пастель, акварель, гуашь белән рәсем) һәм тиражлы басма графика үрнәкләре (металлда гравюра төрләре, ксилография, линогравюра, литография һәм башкалар), шулай ук оригиналь каллиграфия әсәрләре карала;

«Скульптура» (номинациядә төрле жанрдагы әсәрләр карала: монументаль скульптура проектлары, станоклы әсәрләр, вак пластика, материалда башкарылган медальер сәнгать;

«Декоратив сәнгать» (номинациядә декоратив сәнгатьнең төрле төрләре: керамика, тукучылык, агачка чукып эшләү, пыяла, сәнгати металл, сәнгати күн, ювелир сәнгате карала;

«Сәнгать теориясе һәм тарихы, тәнкыйть, сәнгать белеме» (номинациидә фәнни һәм фәнни-популяр басма таләпләренә җавап биргән, рәсем сәнгатенең һәм сәнгати тәнкыйтьнең тарихы, теориясе һәм бүгенге хәле буенча бердәм идеягә корылган хезмәт һәм (яисә) басылган хезмәтләр (мәкаләләр) тупланмасы карала).

1.3. Конкурста профессиональ рәссамнар, скульпторлар, сәнгать белгечләре, рәсем сәнгате һәм декоратив-гамәли сәнгать өлкәсендә фәнни эзләнүләр авторлары катнаша ала (алга таба - катнашучылар).

Конкурста аерым авторлар да, авторлар коллективлары да катнаша ала.

1.4. Конкурс йомгаклары буенча, әлеге Нигезләмәнең 1.2 пунктында күрсәтелгән номинацияләрендә җиңүчеләр «Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының Рәсем сәнгате, декоратив-гамәли сәнгать һәм сәнгать белеме өлкәсендә Бакый Урманче исемендәге премиясен лауреаты» дәрәҗәсенә лаек була һәм һәр номинация буенча 100 000 сум күләмендә акчалата бүләк тапшырыла.

1.5. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының Рәсем сәнгате, декоратив-гамәли сәнгать һәм сәнгать белеме өлкәсендә Бакый Урманче исемендәге премиясен (алга таба – Премия) гамәлгә куючы һәм конкурсын оештыручы булып Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы тора.

## 2. Конкурс үткәрүнең максатлары һәм бурычлары

2.1. Конкурс максатлары булып түбәндәгеләр тора:

бүгенге рәсем сәнгате, декоратив-гамәли сәнгать һәм сәнгать белеме өлкәсендә мәдәният эшлеклеләренә ярдәм итү һәм стимул бирү;

милли сәнгатькә киң җәмәгатьчелекнең игътибарын юнәлтү.

2.2. Конкурс бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

рәсем сәнгате, декоратив-гамәли сәнгать өлкәсендә профессиональ рәссамнар һәм скульпторларның иҗади эшчәнлеген активлаштыру;

милли мәдәният үсешенә зур өлеш керткән, үзенчәлекле автор стиленә ия булган югары профессиональ осталык дәрәҗәсе белән, яңалыгы һәм һәм оригинальлеге белән аерылып торган күренекле әсәрләрне, шулай ук, сәнгать теориясе һәм тарихы, сәнгати тәнкыйть, күргәзмә проектларын һәм акцияләрне барлау;

бүгенге рәсем сәнгате һәм декоратив-гамәли сәнгатьнең популярлашуына һәм республика халкының гомуми культура дәрәҗәсен арттыруга этәргеч бирү.

## 3. Конкурс үткәрү шартлары

3.1. Конкурста катнашу өчен соңгы биш елда иҗат ителгән бер әсәргә яисә әсәрләр сериясенә (алга таба – әсәр) бердән дә артык булмаган гариза тапшырыла.

3.2. Кабул итү вакыты беткәннән соң тапшырылган, шулай ук алдагы конкурслар җиңүчеләре гаризалары конкурска катнашмый.

## 4. Әсәрләрне сайлау критерийлары

4.1. Әсәрләрне конкурс сайлавы түбәндәге сайлау критерийлары нигезендә үткәрелә.

а) тәкъдим ителгән әсәрләрнең номинация таләпләренә туры килүе;

б) алдына куелган сәнгати бурычын үтәүдә авторның осталыгы һәм башкару сыйфатының югарылыгы, эстетик ышандыра алу;

в) әсәрнең сәнгати камиллеге, авторның сайланган материалның табигатенә үтеп керә алып, аның үзенчәлекләрен образлы бурычларны үтәүгә буйсындыру;

г) милли сәнгать традицияләрен дәвам итү;

д) новаторлык формалары;

е) башкаруның иҗади индивидуальлеге.

## 5. Конкурс комиссиясен формалаштыру тәртибе

5.1. Конкурс комиссиясе Татарстан Республикасы мәдәният министры боерыгы белән Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары вәкилләре һәм җәмәгатьчелек арасыннан, шулай ук, Татарстан Республикасының рәсем сәнгате өлкәсендә белгечләре арасыннан туплана.

Конкурс нәтиҗәләре белән шәхсән кызыксынган затлар (шул исәптән конкурста катнашырга гариза бирүчеләр, яисә күрсәтелгән гаризаларны бирүче оешма штатында торучылар) Конкурс комиссиясе әгъзалары була алмый.

5.2. Конкурс комиссиясе эше аның утырышларында алып барыла. Конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми санынннан яртысыннаш артыгы катнашса, утырыш хокуклы дип санала.

5.3. Конкурс комиссиясе карары конкурсның һәр критерие буенча баллар куеп чыгу һәм катнашучыларның рейтингын төзү юлы белән кабул ителә.

5.4. Оештыру-техник эшчәнлекне координацияләү, утырышларны әзерләү һәм документацияне алып бару өчен конкурс комиссиясе рәисе җаваплы секретарьне билгели.

5.5. Конкурс комиссиясенең җаваплы секретаре түбәндәге функцияләрне башкара

Кергән тәртиптә конкурс гаризаларын кабул итә һәм терки;

Конкурс комиссиясе утырышында карау өчен материаллар әзерли һәм аларның саклануын оештыра;

Конкурс комиссиясе утырышы беркетмәләрен тутыра.

Конкурс комиссиясенең җаваплы секретаре конкурс комиссиясе составына керми һәм утырышларда тавыш бирү хокукыннан башка гына катнаша.

5.6. Конкурс комиссиясе утырышы беркетмәләре утырыш уздырылганнан соң өч эш көне эчендә аның рәисе тарафыннан раслана һәм расланганнан соң 5 эш көне эчендә Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының рәсми сайтында урнаштырыла.

## 6. Конкурс үткәрү тәртибе

6.1. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы боерыгы чыкканнан соң ике эш көне эчендә Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының рәсми сайтында конкурс үткәрелү турында игълан урнаштырыла, анда конкурсның вакыты, урыны һәм тәртибе, конкурс гаризаларын кабул итэ башлау һәм кабул ителү тәмамлануы вакытлары турында белешмә бирелә.

6.2. Конкурста катнашу өчен гаризалар кабул ителү конкурс үткәрелү турында игълан Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылганнан соң 30 календарь көне эчендә башкарыла.

6.3. Конкурста катнашу өчен икедән дә кимрәк гариза бирелсә, конкурс үтмәгән булып таныла.

6.4. Конкурста катнашу өчен катнашырга теләүчеләр Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына конкурс гаризасы тапшыралар. Аның эченә түбәндәге документлар керә:

Конкурста катнашу өчен әлеге Нигезләмәнең кушымтасы үрнәгендәге гариза;

Премия алу өчен тәкъдим ителгән әсәрнең яисә әсәрләрнең төп нөсхәсе;

гариза бирүченең иҗаты турында белешмә (рецензия);

гариза бирүченең әсәрен (әсәрләр сериясе) күзалларга ярдәм итүче өстәмә материал (фоторәсемнәр, мәкаләләр, рецензияләр).

6.5. Тапшырыла торган гаризаның бөтен пунктлары да тутырылган булырга тиеш. Тапшырыла торган документлар гариза бирүче тарафыннан имзалана. Конкурс гаризасының бөтен битләре дә тегелгән, номер сугылган булырга тиеш.

6.6. Конкурс гаризасы Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына кәгазьгә бастырылып тапшырыла.

6.7. Конкурс шартларына туры килмәү, конкурс гаризасында кирәкле документлар булмау, документларда дөрес булмаган белешмәләр күрсәтелү гариза бирүчене конкурста катнаштырудан баш тарту өчен нигез булып тора ала.

6.8. Конкурска катнаштырудан баш тарткан очракта Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы гариза бирүчегә бу хакта өч эш көне эчендә хәбәр итә.

6.9. Әлеге Нигезләмә турында мәгълүмат һәм гариза үрнәге Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының рәсми сайтында (www.mincult.tatar.ru) урнаштырыла.

6.10. Конкурс гаризасы әзерләү чыгымнарын гариза бирүче үзе күтәрә.

6.11. Конкурс гаризалары Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына керү тәртибендә өч эш көне эчендә теркәлә.

6.12. Кабул итү вакытыннан соңга калып тапшырылган Конкурс гаризалары конкурска катнаштырылмый.

6.13. Әлеге Нигезләмәгә туры китерелеп каралган Конкурс гаризалары Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгында 3 (өч) ел саклана.

6.14. Конкурс гаризалары кабул ителү тәмамлангач, 3 эш көне эчендә конкурс комиссиясенең башлангыч утырышы уздырыла, анда тәкъдим ителгән әсәрләрнең конкурс шартларына туры килүе карала һәм конкурста катнашучылар исемлеге игълан ителә.

6.15. Конкурста катнашучылар исемлеген формалаштыру конкурс комиссиясенең башлангыч утырышы беркетмәсендә чагыла, анда конкурс гаризалары саны һәм конкурста катнашучылар исемнәре һәм тәкъдим ителгән әсәрләре күрсәтелә. Конкурс комиссиясенең башлангыч утырышы беркетмәсе әлеге Нигезләмәнең 5.5 пунктына туры китереп тутырыла һәм раслана.

6.16. Конкурс комиссиясенең башлангыч утырышыннан соң 14 көн эчендә конкурс комиссиясе конкурс уздыра һәм тәкъдим ителгән әсәрләрне әлеге Нигезләмәнең 4нче бүлегендә билгеләнгән критерийлар нигезендә 5 баллы шкала буенча (0 дән 5кә кадәр) бәяли.

6.17. Тавышлар тигез булган очракта конкурс комиссиясе рәисенең тавышы хәлиткеч булып санала.

6.18. Баллар суммасы буенча конкурс комиссиясе һәр номинация буенча конкурста катнашучыларның рейтингын төзи. Һәр номинация буенча иң күп балл җыйган катнашучылар җиңүче була.

6.19. Конкурс комиссиясе рейтинг нигезендә 2 эш көне эчендә конкурс җиңүчеләренең биреләсе Премия күләме күрсәтелгән исемлеген төзи, исемлек 3 эш көне эчендә Татарстан Республикасы мәдәният министры боерыгы белән раслана.

6.20. Конкурс җиңүчеләре исемлеге расланганнан соң 5 эш көне эчендә Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының рәсми сайтында урнаштырыла.

6.21. Конкурс үткәрелгән вакытта киң җәмәгатьчелекне номинантларның эшләре белән таныштыру максатыннан күргәзмә оештырыла, ул конкурс үткәрелгән вакытта Казан шәһәре күргәзмә залларының берсендә уза. Күргәзмәнең урыны һәм вакыты турында мәгълүмат күргәзмә ачылырга 2 эш көне кала Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының рәсми сайтында урнаштырыла.

6.22. Конкурс йомгаклары суд тәртибендә генә яңадан карала ала.

## 7. Конкурс җиңүчеләрен бүләкләү

7.1. Конкурс җиңүчеләренә һәр номинация буенча «Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының Рәсем сәнгате, декоратив-гамәли сәнгать һәм сәнгать белеме өлкәсендә Бакый Урманче исемендәге премиясе лауреаты» дигән дәрәҗәле исем бирелә.

7.2. Конкурс җиңүчеләре һәр номинациядә диплом һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының керемнәр һәм чыгымнар җыелма сметасында каралган акчалар хисабыннан конкурста җиңүченең банкта ачылган исәп-хисап счетына күчерелгән 100 000 сум күләмендә акчалы премия белән бүләкләнә.

7.3. Премия бер авторга яки авторлар коллективына бирелә.

7.4. Премия авторлар коллективына бирелгәндә дипломнар лауреатларның һәрберсенә бирелә, ә Премия түбәндәгечә бүленә:

- коллектив җитәкчесенә Премиянең өчтән бере бирелә, ә өчтән ике өлеше коллективның калган әгъзалары арасында тигез өлешләргә бүленә;

- авторлар коллективы җитәкчесен тәкъдим итмәсә, Премия коллективның бөтен әгъзалары арасында тигез өлешләргә бүленә.

7.6. Премия Татарстан Республикасы мәдәният министры боерыгы нигезендә түләнә.

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының
Рәсем сәнгате, декоратив-гамәли сәнгать һәм
сәнгать белеме өлкәсендә Бакый Урманче исемендәге
премиясен алу өчен республика конкурсы турында
әлеге Нигезләмәгә кушымта

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының Рәсем сәнгате, декоратив-гамәли сәнгать һәм сәнгать белеме өлкәсендә Бакый Урманче исемендәге премиясен алу өчен республика конкурсына катнашу өчен

**ГАРИЗА**

Ф.И.ӘИ. ________________________________________________

Туган көне ______________________________________________

Өй адресы, телефон, факс, e-mail_______________________________

________________________________________________________

Белеме___________________________________________________

Күргәзмәләрдә катнашу_____________________________________

Аавтор (авторлар) турында мәкаләләр___________________________

Конкурска тәкъдим ителгән әсәрләр турында белешмә:__________________

*«Рәсем сәнгате», «Графика», «Скульптура» и «Декоратив сәнгать» номинацияләре өчен түбәндәгеләрне күрсәтү мәҗбүри:

номинациянең төре;

эшнең атамасы;

иҗат ителгән ел;

материал, техника, зурлыгы.

«Персональ мәгълүматлар турында» 27.07.2006 ел, №152-ФЗ Федераль законга туры китереп, персональ мәгълүматларны эшкәртергә ризалык бирәм.

_______________________ /____________________ /

имза